**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

11.11.2024 № 1365

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен булдыру турында» 2024 елның 18 октябрендәге 1250 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында Нигезләмәне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы карары, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы турында» 2020 елның 20 февралендәге 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы, Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау турында» 2008 елның 14 ноябрендәге 687 номерлы боерыгы белән, техник хата җибәрелүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында гражданнар оборонасы һәм коткару хезмәтләрен булдыру чараларын тәэмин итү турында» 2024 елның 18 октябрендәге 1250 номерлы карарына 2нче кушымтага үзгәрешләр кертергә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында коткару хезмәтләрен булдыру һәм аларның эшчәнлеген әлеге карарга 1нче кушымта нигезендә яңа редакциядә гамәлгә ашыру тәртибен бәян итәргә.
2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында гражданнар оборонасы һәм коткару хезмәтләрен булдыру чараларын тәэмин

итү турында» 2024 елның 18 октябрендәге 1250 карарына 3 нче кушымтага үзгәрешләр кертергә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы коткару хезмәтләре структурасын әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә калдырырга.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин